| МИНИСТЕРСТВО ЗДРАВООХРАНЕНИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**03.01.2023** г. Казань № 4

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган бәяләү битенең формасын раслау турында

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 191 статьясындагы 8 өлеше нигезендә, «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше эшчәнлеген лицензияләү, наркотиклы үсемлекләр үстерү турында» 2022 елның 2 июнендәге 1007 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Наркотик, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше эшчәнлеген лицензияләү, наркотиклы үсемлекләр үстерү турында нигезләмәнең 4 пунктындагы «б» пунктчасы нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган кушымта итеп бирелгән бәяләү битенең формасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 06.06.2022 ел, № 1616 «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда оешмаларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган бәяләү битенең формасын раслау турында»боерыгы үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры урынбасары В.В.Виниченкога йөкләргә.

Министр М.Н.Садыйков

Татарстан Республикасы
Сәламәтлек саклау
министрлыгы боерыгы белән
расланды
03.01.2023№ 4

Форма

**Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның исемлекнең I-III исемлегенә кертелгән наркотик һәм психотроп матдәләрнең әйләнеше эшчәнлеген башкарганда юридик затларның, дару чаралары белән күпләп сату оешмаларыннан һәм башкарма хакимиятнең федераль органнары карамагындагы даруханә оешмаларыннан тыш, лицензия таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләүне үткәрелә торган**

**бәяләү бите**

1. Лицензиягә дәгъва кылучының яки лицензиатның лицензия таләпләренә туры килүен бәяләү формасы, теркәлү номеры һәм лицензия бирү турында гаризаны теркәү датасы (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү):

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

2. Тулы яисә кыскартылган исеме (булган очракта), һәм юридик затның оештыру-хокукый рәвеше, аның урнашу урыны адресы, юридик затның төп дәүләт теркәү номеры (ОГРН):

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

3. Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адресы (адреслары):

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

4. Бәяләү битен тутыру белән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүне үткәрү урыны (урыннары):

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

5. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кабул ителгән лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләү үткәрү турындагы карар реквизитлары:

______________________________________________________________________

6. Лицензия таләпләренә туры килү-килмәүне бәяләүче һәм бәяләү кәгазе тутыручы Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының вазыйфаи заты вазыйфасы, фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта):

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

7. Лицензия алырга теләүченең яки лицензиатның лицензиат таләпләренә туры килүе (туры

килмәве) турында таныкларга тиешле контроль сораулар исемлеге:

| № п/п | Лицензия таләпләре эчтәлеген чагылдыра торган контроль сораулар исемлеге | Лицензия таләпләре билгеләнгән структур берәмлекләрен күрсәтеп, норматив хокукый актлар реквизитлары | Лицензия таләпләренә туры килү (туры килмәү) турындагы сорауларга җаваплар | | | Искәр мәләр |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | әйе | юк | Кул ланыл мый | |
| 1 | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен үзенә милек хокукында яки башка законлы нигездә бирелгән кирәкле урыннары бармы? | «Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше эшчәнлеген лицензияләү, наркотиклы үсемлекләр үстерү турында» 2022 елның 2 июнендәге 1007 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше эшчәнлеген лицензияләү, наркотиклы үсемлекләр үстерү турында нигезләмәнең 5 пунктының «а» пунктчасы, (6 пунктның «а» пунктчасы)(алга таба | Нигез ләмә) | | | |
| 2 | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) милек хокукында яки башка законлы нигездә Россия Федерациясендә контрольгә алынырга тиешле наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлегенең I-III исемлегенә кертелгән наркотик чаралар, психотроп матдәләр әйләнеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен кирәкле җиһазларга ияме (алга таба – наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр исемлеге)? | Нигезләмәнең 5 пунктының «а» пунктчасы (6 пунктның «а» пунктчасы) | | | | |
| 3 | Медицина оешмасы - лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) медицина эшчәнлеген башкаруга | Нигезләмәнең 5 пунктының «б» пунктчасы (6 пунктның «б» пунктчасы) | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | лицензиясе бармы? | | | | | |
| 4 | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) бу затларны Россия Федерациясе наркотиклар, психотроп матдәләр, прекурсорлар турында законнары белән таныштыру өлешендә наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә затларны кертү тәртибен һәм хезмәт килешүенә наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм (яки) прекурсорлар әйләнешенә бәйле затларны һәм оешмаларның үзара йөкләмәләрен кертү тәртибен саклыймы? | Нигезләмәнең 5 пунктының «в» пунктчасы (6 пунктның «в» пунктчасы) 2022 елның 20 маендагы 911 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары белән расланган Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә, шулай ук наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр прекурсорлары әйләнешенә бәйле эшчәнлеккә затларны наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә кертү кагыйдәләренең 3 пункты (алга таба – Кертү кагыйдәләре) | | | | |
| 5 | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) хезмәткәрләрнең үз вазыйфалары нигезендә турыдан-туры наркотик чараларга һәм психотроп матдәләргә уртача авырлыктагы җинаять, авыр һәм аеруча авыр җинаять яки наркотик чараларның, психотроп матдәләрнең һәм аларның прекурсорларының законсыз әйләнеше яки наркотиклы үсемлекләрне законсыз үстерү белән бәйле җинаять өчен, шул исәптән Россия Федерациясеннән читтә кылынган җинаять өчен дә үтәлмәгән яки бетерелмәгән җинаятьләргә керү мөмкинлеге биреләчәк булмавы турында эчке эшләр органнары булу өлешендә наркотик һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә затларны кертү тәртибен | Нигезләмәнең 5 пунктының «в» пунктчасы (6 пунктның «в» пунктчасы) Кертү кагыйдәләренең пункт 4, 7 | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | саклыймы? | | | | | |
| 6 | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) наркотик һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә, шулай ук наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр прекурсорлары әйләнешенә бәйле эшчәнлеккә, җитәкченең наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр белән эшләргә рөхсәт итү турындагы карары булу өлешендә, шулай ук наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр прекурсорлары әйләнешенә бәйле эшчәнлеккәзатларны кертү тәртибен саклыймы? | Нигезләмәнең 5 пунктының «в» пунктчасы (6 пунктның «в» пунктчасы)<br>пункт 8 Правил допуска;<br><br>«Наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр турында» 1998 елның 8 гыйнварындагы 3-ФЗ номерлы Федераль законның<br>10 статьясындагы 3 пунктының бишенче абзацы (алга таба - № 3-ФЗ Федераль законы) | | | | |
| 7 | Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) үз хезмәт бурычлары нигезендә наркотикларга, исемлекнең I прекурсорларга кертелгән психотроп матдәләргә, наркомания, токсикомания, хроник алкоголизмга ия булырга тиеш, медицина оешмалары тарафыннан Сәламәтлек саклау дәүләт системасының яки муниципаль сәламәтлек саклау системасының хезмәткәрләрнең булмавы турында бирелгән белешмәләрнең булуы өлешендә, наркотик һәм психотроп матдәләр белән эшләүгә затларны кертү тәртибен саклыймы? | Нигезләмәнең 5 пунктының «в» пунктчасы (6 пунктның «в» пунктчасы)<br>Кертү кагыйдәләренең 4 пунктның «б» пунктчасы, 6 пункт | | | | |
| 8 | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше буенча эшчәнлек алып бару нияте булган, эшчәнлек башкарыла торган объектларның һәм биналарның инженер-техник чаралар белән җиһазландыруга | Нигезләмәнең 5 пунктының «в» пунктчасы (6 пунктның «в» пунктчасы)<br>№ 3-ФЗ Федераль законының 10 статьяның 3 пунктындагы өченче абзацы | | | | |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | билгеләнгән таләпләргә туры килүе турында Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары бәяләмәсе бармы? | | | | | |
| 9 | Лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) наркотик чаралар һәм психотроп матдәләр әйләнеше буенча эшчәнлек алып бару нияте булган, тиешле һөнәри әзерлеге булган белгеч җитәкчеләре составында бармы? | Нигезләмәнең 5 пунктының «ж» пунктчасы (6 пунктның «э» пунктчасы) № 3-ФЗ Федераль законының 10 статьяның 1 пункты | | | | |

«Наркотик чаралар, психотроп матдәләр һәм аларның прекурсорлары әйләнеше эшчәнлеген лицензияләү, наркотиклы үсемлекләр үстерү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 2 июнендәге 1007 номерлы карары белән каралган лицензия таләпләренә туры килүе/туры килмәве ачыкланды (кирәклесен билгеләргә).

________________________________________ ____________________

(туры килү-килмәүне бәяләгән һәм бәяләү битен тутырган вазыйфаи зат) (имза)

Бәяләү битен тутыру датасы
«____»_______________20_____г.